СОВЕТ НИКОЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422627 с. Никольское,
ул. Центральная, д.35
тел: 4-31-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422627 Никольский авылы,
Әзәк урамы, 35 нчы йорт,
тел: 4-31-44

**2024лның 11 ноябре** **78 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегенең Сапуголи торак пунктында гражданнар җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлегендәге Сапуголи торак пункты гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегенең Сапуголи торак пункты территориясендәяшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым салу акчаларын 5000 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; («Никольские луга» КП,» Восточные Сапуголи» КП, « Ново-Никольское» КП, « Добрый»КП)

- урамнарны яктырту җайланмасы; (КП « Никольские Луга», КП «Ново-Никольское»,

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Сапуголы авылы, Добрый поселогы)

3. Әлеге карарны Никольский авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Рәислек итүче: _________________ А.Н.Пашагин

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Никольский
авыл җирлеге Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы_________________ А.Н.Пашагин